РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

30 декабрь 2021 ел №85

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрне (авыл җирлекләрен) шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы нигезендә, шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслауга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Шәһәр төзелешен проектлау нормативларын әзерләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» 2021 елның 15 февралендәге 71 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау һәм аларга Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең (авыл җирлекләренең) үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 65 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Халыкны җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен үз эченә ала торган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрне (авыл җирлекләрен) шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын расларга:

- Бәркәтә авыл җирлегенең 1 нче кушымта нигезендә;
- Югары Кәминкә авыл җирлегенең 2 нче кушымта нигезендә;
- Ивашкино авыл җирлегенең 3 нче кушымта нигезендә;
- Кармыш авыл җирлегенең 4 нче кушымта нигезендә;

- Күтәмә авыл җирлегенең 5 нче кушымта нигезендә;
- Лашман авыл җирлегенең 6 нчы кушымта нигезендә;
- Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең 7 нче кушымта нигезендә;
- Түбән Кәминкә авыл җирлегенең 8 нче кушымта нигезендә;
- Түбән Кармалка авыл җирлегенең 9 нчы кушымта нигезендә;
- Яңа Элмәле авыл җирлегенең 10 нчы кушымта нигезендә;
- Яңа Кади авыл җирлегенең 11 нче кушымта нигезендә;
- Иске Кади авыл җирлегенең 12 нче кушымта нигезендә;
- Иске Котыш авыл җирлегенең 13 нче кушымта нигезендә;
- Иске Үтәмеш авыл җирлегенең 14 нче кушымта нигезендә;
- Туймәт авыл җирлегенең 15 нче кушымта нигезендә;
- Ульяновка авыл җирлегенең 16 нчы кушымта нигезендә;
- Чирмешән авыл җирлегенең 17 нче кушымта нигезендә;
- Шешминка авыл җирлегенең 18 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрне шәһәр төзелеше проектлауның расланган нормативларын территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында әлеге карар кабул ителгән көннән 5 (биш) көннән дә артмаган вакытта урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль район
башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин